КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 март г.Казань № 287

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 31 октябрь, 1162 нче карары белән расланган Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затларга әлеге юридик затлар милкендәге капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрация элементлары белән, техник яңадан җиһазлау) һәм яки алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен капиталь төзелеш объектларына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затларга әлеге юридик затлар милкендәге капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрация элементлары белән, техник яңадан җиһазлау) һәм яки алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен капиталь төзелеш объектларына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 ел, 31 октябрь, 1162 нче карары белән расланган Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик

затларга әлеге юридик затлар милкендәге капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрация элементлары белән, техник яңадан җиһазлау) һәм яки алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен капиталь төзелеш объектларына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләренә, 3 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«б) Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәләре һәм күрсәтмәләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәләре;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин